| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-106/тэ

«Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелүче хезмәтләргә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карарның 2 кушымтасы нигезендә 2019-2023 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-106/тэ карарына 1 нче кушымта

## «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 454,30 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 465,79 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 465,79 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 476,71 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 476,71 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 489,20 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 489,20 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 499,87 | - |
| | | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 499,87 | - |
| | | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 515,28 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-106/тэ карарына 2 нче кушымта

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2019-2023 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җылылык челтәренең матди сыйфатламасына карата сарыфлар күләме | Технологик сарыфлар |
| | | | мең сум | % | Гкал/$м^2$ | Гкал |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | |
| 1 | «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте | 2019 | 317480,23 | 1 | 2,92 | 222441,0 |
| | | 2020 | X | 1 | 2,92 | 222441,0 |
| | | 2021 | X | 1 | 2,92 | 222441,0 |
| | | 2022 | X | 1 | 2,92 | 222441,0 |
| | | 2023 | X | 1 | 2,92 | 222441,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге